МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.04.2021 г.Казань № 275

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 26 маенда 7687 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 29 апрелендәге 2021 елның 275 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 191 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №440, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №353, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №327, 13.09.2019 №703, 14.11.2019 №1016, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698, 22.12.2020 №886 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – Татарстан Республикасында яшәүче, бер үк вакытта туган өч һәм аннан күбрәк баланың ата-анасы (опекуннары, уллыкка алучылар, тәрбиягә бала алган ата-аналар) булып торган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мөрәҗәгать итүче).»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.»;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1). Банк яки башка кредит учреждениесендә ачылган (бер бирелә торган пособиене банк аша алганда) шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, бер бирелә торган пособиене билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

2) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәс белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин;

3 нче бүлектә:

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече вәкаләтле органнардан электрон рәвештә бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүмат ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат алу.»;

3.8.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында имзаланган карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Берьюлы өч һәм аннан күбрәк
бала туганда бер мәртәбә түләнә
торган пособие билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү турында карар

№_________ «__» _________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_______________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ____________________________________

Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләргә

Балалар өчен _______________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Түләү ысулы

_______________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе

_______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) _____________________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм
(компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ
№_ бүлекчәсе белгече
_________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ________________________ ______________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада________________________________________
__________________________________________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ___________________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________
(электрон почта адресы)
бүлекчә белгече ___________________________ ____________
(Ф.И.А.) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләүдән баш тарту турында карар

№_____ «__» ____________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) ______________________________________________________________
Мөрәҗәгать итүченең адресы _____________________________________________
Бер үк вакытта өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособиене билгеләүдән баш тартырга
Балалар өчен ______________________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)
Баш тарту сәбәбе: __________________________________________________________

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе җитәкчесе
_______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ________________________________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге» ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече

_______________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

_________________________ ___________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада_______________________________________
______________________________________________________________________
әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ___________________________________________
(телефон номеры)
электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ________________________________
(электрон почта адресы)
бүлекчә белгече ____________________________ ___________
(Ф.И.А.) имза;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Берьюлы өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер мәртәбә түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

РМЯ(КТ)Ү №_____ бүлекчәсе
___________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ______________________________________________________
______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
______________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ
атамасы, аның сериясе, номеры, бирелү датасы,
______________________________________________________________________
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ______________________________________,
______________________________________________________________________
_____________________________________________________________________,
берьюлы өч һәм аннан да күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарда җибәрелгән,
_____________________________________________________________________.

(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Бер үк вакытта өч һәм аннан күбрәк бала туганда бер мәртәбә бирелә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында мәгълүмат алуга риза

____________________________________________________________________________

(почта адресына язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп)

«__» ________ 20__ ел. __________________________ ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 8 апрелендәге 221 номерлы боерыгы белән расланган (Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 26.07.2016 №441, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 07.05.2019 №327, 13.09.2019 №703, 14.11.2019 №1016, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698, 22.12.2020 №886 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – Татарстан Республикасында яшәүче, бер үк вакытта туган өч һәм аннан күбрәк баланың ата-анасы (опекуннары, уллыкка алучылар, тәрбиягә бала алган ата-аналар) булып торган Россия Федерациясе гражданнары (алга таба – мөрәҗәгать итүче).»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте «Республикасы матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Үзәк бүлекчәсендә (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) күрсәтелә.»;

2 бүлектә 2.5 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1). Банк яки башка кредит учреждениесендә ачылган (айлык пособиене банк аша алганда) шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, айлык пособиене билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән;

2) чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе;

3) граждан хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәс белгече тарафыннан таныклана.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин;

3 нче бүлектә:

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече вәкаләтле органнардан электрон рәвештә бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүмат ала.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мәгълүмат алу.»;

3.8.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Үзәк бүлекчәсе белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 3 нче кушымтасы);

ай саен түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерә;

ай саен түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны имзалау өчен Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен юлланган ай саен түләүнә торган пособие билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 3 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

киңәш ителә торган рәвеше

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ай саен түләнә торган пособие билгеләү турында карар

№__________ «__» __________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)
________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ________________________________________

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие билгеләргә

Балалар өчен ________________________________________________
(Фамилия, исем, ата исеме)

Түләү ысулы
________________________________________________________________

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ №___ бүлекчәсе житәкчесе
________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында) ___________ ______________________
(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм (компенсацион түләүләр) үзәге»

ДКУ _ номерлы бүлекчәсе белгече

______________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) __________________ ______________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):

әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________

_______________________________________________________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча _____________________________

(электрон почта адресы)

бүлек белгече _________________________________ ____________

(Ф.И.А.) имза

«Матди ярдәм (компенсация түләүләре) республика үзәге» ДКУ №_____ бүлекчәсе

_______________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында)

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ай саен түләнә торган пособие билгеләүдән баш тарту турында карар

№_____ «__» ____________

Мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта)

_______________________________________________________________________

Мөрәҗәгать итүченең адресы ___________________________________________

Берьюлы туган өч һәм аннан күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга

Балалар өчен ______________________________________________________________

(Фамилия, исем, ата исеме)

Баш тарту сәбәбе: __________________________________________________________

Республика матди ярдәм

(компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ

№___ бүлекчәсе җитәкчесе

__________________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) ____________________________________________

(фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Мөһер урыны

«Республика матди ярдәм

(компенсацион түләүләр) үзәге»

ДКУ _ номерлы бүлекчәсе
белгече

_______________________________

муниципаль районында (шәһәр округында) (фамилия, исем, ата исеме) (имза)

Хәбәр итү ысулы (кирәклесе астына сызарга):
әлеге адрес буенча язмача формада____________________________________

_____________________________________________________________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ______________________________
(телефон номеры)

электрон документ формасында
әлеге электрон почта адресы буенча ____________________________________
(электрон почта адресы)

бүлекчә белгече ________________________ ____________
(Ф.И.А.) имза»;

Регламентка 5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ел ярымга кадәр ай саен түләнә торган пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

РМЯ(КТ)Ү №_____ бүлекчәсе

_____________________________
муниципаль районында (шәһәрендә)

Техник хатаны төзәтү турында гариза

Мин, ____________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча күрсәтелә)
яши торган адрес: ______________________________________________________

_____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)

_____________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ атамасы,
аның сериясе, номеры, бирелү датасы,

_____________________________________________________________________________
документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм ___________________________________________,

_____________________________________________________________________________

_____________________________________________________________________________,

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ай саен түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарда җибәрелгән ______________________________

(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Берьюлы туган өч һәм аннан да күбрәк бала тәрбияли торган гаиләләргә ай саен түләнә торган пособие билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карарны үзгәртеп рәсмиләштерү турында мәгълүмат алуга риза

______________________________

(почта адресына язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп)

«__» ________ 20__ ел. ____________________ ________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы) (тулы имза)».

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемы түләүдән азат итү, балага кирәк-яракларының бүләк комплектын алу өчен гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керем күләме яки ялгыз яши торган гражданинның кереме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 11 июлендәге 397 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №348, 18.09.2018 №885, 02.07.2019 №509; 15.11.2019 №1032, 03.02.2020 №52, 25.06.2020 №461, 05.10.2020 №698 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Түләүсез юридик ярдәм алу, курорт җыемы түләүдән азат итү, балага кирәк-яракларының бүләк комплектын алу өчен гаиләнең җан башына исәпләгәндә уртача керем күләме яки ялгыз яши торган гражданинның кереме турында белешмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлекчәсе (алга таба – Үзәк бүлекчәсе) тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны яки торган урыны буенча – әлеге Регламентның 1.2 пунктының 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен, мөрәҗәгать итүченең яшәгән урыны буенча – әлеге Регламентның 1.2 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен.»;

2 бүлектә:

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада белешмә бирү турында гариза.

2) Гаризаны тапшырган айдан алдагы өч ай өчен гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан алынган керемнәр турында документлар күчермәләре, шул исәптән:

отставкага киткән судьяларга гомер буе ай саен түләнә тәэминат күләме турында белешмә күчермәсе;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре күләме турында белешмә күчермәсе;

контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие күләме турында белешмә күчермәсе;

Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эшкә урнаштыру мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына айлык компенсация түләүләре күләме турында белешмә күчермәсе;

гаилә әгъзалары ала торган алиментлар күләме турында документ күчермәсе;

дәүләт бурычларын яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында белешмә күчермәсе;

хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты күләме турында белешмә күчермәсе;

хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие күләме турында белешмә күчермәсе;

мирас итеп бирелә торган яки бүләк ителгән акчалар күләме турында документ күчермәсе.

3) Чит ил дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.

4) Гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында чит дәүләтнең компетентлы органы тарафыннан бирелгән таныклык күчермәсе һәм аның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә күчермәсе.

5) Гражданлык хәле актларын теркәү органы яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениесе тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклык күчермәсе (уллыкка алучы мөрәҗәгать иткән очракта).

6). Мөрәҗәгать итүченең гаилә әгъзаларының аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы булуын һәм мөрәҗәгать итүченең шәхси мәгълүматларны Үзәк бүлекчәсенә тапшырганда алар исеменнән эш итүгә вәкаләтләре булуын раслый торган документ.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итү вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлекчәсе белгечләре тарафыннан таныклана.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлекчәсенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гаризаны шулай ук Үзәк бүлекчәсендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аны мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, имзалый.

Гариза һәм документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләренә туры китереп, электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре аша да, тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча вәкаләтле органнардан түбәндәге документлар һәм белешмәләр алына:

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

йөкле хатын-кызны медицина учреждениесенә исәпкә кую турында - йөкле хатын-кыз мөрәҗәгать иткән очракта;

Федераль салым хезмәтендә булган физик затларның һәм гаилә әгъзаларының керемнәре турында;

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр турында.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк бүлекчәсе мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүмат тапшыруны»;

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлекчәсе белгече электрон формада вәкаләтле органнардан түбәндәге мәгълүматларны ала:

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган мәгълүматлар.»;

3.4.2 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Белешмә бирү турында (бирүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлекчәсендә булмаганда, Үзәк бүлекчәсе белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында вәкаләтле органнарга рәсми мөрәҗәгатьләр җибәрә:

яшәү (вакытлыча тору) урыны буенча мөрәҗәгать итүче белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында;

шәхси счетның иминият номеры турында;

опека (химаяче) билгеләү һәм опекунның (химаяченең) баланы асрауга акча алуы турында;

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-ана хокукында чикләнү турында;

йөкле хатын-кызны медицина учреждениесенә исәпкә кую турында - йөкле хатын-кыз мөрәҗәгать иткән очракта;

Федераль салым хезмәтендә булган физик затларның һәм гаилә әгъзаларының керемнәре турында;

барлык дәрәҗәдәге бюджетлардан, бюджеттан тыш дәүләт фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. Шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтә торган органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

Регламентка 5 нче кушымтада «мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителде (кирәклесе астына сызарга)» сүзләрен «Хәбәр итү ысулы» сүзләренә алмаштырырга.